РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.03.2020 №45-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Генераль планы проекты турында фикер алышу буенча җәмәгать тыңлаулары билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы авыл җирлекләренең Генераль планнары проектлары турында фикер алышу мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турындагы мөрәҗәгатен караганнан соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24 һәм 28 статьялары һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 елның 21 декабрендәге 94 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районында җәмәгать тыңлаулары турындагы Нигезләмә нигезендә, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре булып торуын һәм авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып һәм халыкның җәмәгать тыңлаулары аша фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатларында

КАРАР БИРӘМ:

**1**. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрүне 2020 елның 24 апреленә билгеләргә.

**2.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча җәмәгать тыңлауларын түбәндәге адреслар буенча үткәрергә:

– Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Көек авылы, Татарстан урамы, 25 йорт, Көек авыл клубы бинасы, 13: 00 сәгатьтә;

– Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Кызыл Мишә авылы, Ленин урамы, 32 йорт, Кызыл Мишә авыл мәдәният йорты бинасы, 14: 00 сәгатьтә;

– Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Тимершык авылы, Пионерская урамы, 19а йорты, Тимершык авыл мәдәният йорты бинасы, 15.00 сәгатьтә;

– Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Мингәр авылы, Татарстан урамы, 23 йорт, Мингәр авыл клубы бинасы, 16.00 сәгатьтә;

– Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Сабай авылы, Г.Тукай урамы, 23а йорты, Сабай авыл клубы бинасы, 17.00 сәгатьтә.

**3.** Җәмәгать тыңлауларын Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 елның 21 декабрендәге 94 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районында җәмәгать тыңлаулары турында Нигезләмәдә билгеләнгән тәртип буенча уздырырга.

**4.** Фикер алышына торган мәсьәләләр буенча язмача тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр, шулай ук чыгыш ясау хокукы белән җәмәгать тыңлауларында катнашу өчен гаризалар Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т. б., Г. Закиров урамы, 52 йорт, 105 каб. адресы буенча тапшырылырга мөмкин. (эш көннәрендә-8.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр). Чыгыш ясау хокукы белән җәмәгать тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 2020 елның 23 апреле. Тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр язмача яки телдән җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның җыелышын үткәрү вакытында да бирелергә мөмкин.

**5.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына:

– халыкка җәмәгать тыңлаулары үткәрелә башлау турында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм авыл җирлеге бинасы янында җиһазландырылып куелган авыл җирлегенең мәгълүмат такталарында, гражданнар күпләп җыела торган урыннарда һәм җирлек территориясендә урнашкан башка урыннарда, шулай ук җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның әлеге мәгълүматка үтемлелеген тәэмин итә торган башка ысуллар белән түбәндәгеләрне урнаштыру юлы аша хәбәр итәргә:

1) җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат һәм аңа карата мәгълүмати материаллар, җыелышны яисә җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның җыелышларын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат;

2) җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проект турында мәгълүмат һәм мондый проектка мәгълүмати материаллар исемлеге;

3) җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проект буенча җәмәгать тыңлаулары уздыру тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат;

4) җәмәгать тыңлауларында каралырга тиеш булган экспозициянең яисә проект экспозицияләренең урыны, датасы, экспозицияне яки мондый проект экспозицияләрен үткәрү сроклары, күрсәтелгән экспозицияне яки экспозицияләрне карау мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат;

5) җәмәгать тыңлауларында катнашучылар тарафыннан җәмәгать тыңлауларында каралачак проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр кертү тәртибе, вакыты һәм формасы турында мәгълүмат;

– Генераль план проектын һәм аңа кагылышлы мәгълүмати материалларны “Интернет” челтәрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга;

– 2020 елның 24 мартыннан 2020 елның 23 апреленә кадәр, ТР, Саба муниципаль районы, Тимершык авылы, Пионерская урамы, 19а йорты адресы буенча урнашкан Күпфункцияле үзәк бинасында ачык тыңлауларда каралырга тиешле Генераль план проектының экспозицияләрен ачарга һәм үткәрергә. Экспозицияне эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр карарга мөмкин. Экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә консультация бирү, җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проект турында мәгълүмати материаллар тарату оештырылырга тиеш.

– гражданнар һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен кабул итү һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә;

**6.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә:

– 2020 елның 23 мартына кадәр әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

– җәмәгать тыңлауларына әзерлекне, билгеләнгән сроклар буенча җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның җыелышларын үткәрүне тәэмин итәргә;

– җәмәгать тыңлаулары беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

– җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

**7.** Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

**8**. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Закирҗановка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов